**Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы**
**Шумково авыл җирлеге Советы**

КАРАР № 4

Шумкво авылы 2025 елның 17 феврале

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Шумково авыл җирлеге Советының 2023 елның 13 Октябрендә “Җир салымы турынла” гы 20 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

«Россия Федерациясе Салым кодексының беренче һәм икенче өлешләренә, Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү һәм Россия Федерациясе закон актларының аерым нигезләмәләренең үз көчләрен югалтуын тану турында»2024 елның 12 июлендәге 176-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы “Шумково авыл җирлеге”муниципаль берәмлеге Уставына таянып, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Шумково авыл җирлеге Советы КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Шумково авыл җирлеге Советының 2023 елның 13 Октябрендә “Җир салымы турынла” гы 20 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1) 2 пунктның 4 абзацындагы «(эшкуарлык эшчәнлегендә файдаланыла торган индивидуаль торак төзелеше өчен сатып алынган (бирелгән) җир кишәрлекләреннән гайре)» сүзләрен «әлеге абзацта күрсәтелгән индивидуаль торак төзелеше өчен сатып алынган (бирелгән) эшкуарлык эшчәнлегендә файдаланыла торган җир кишәрлекләреннән һәм һәркайсының кадастр бәясе 300 миллион сумнан артып китә торган җир кишәрлекләреннән гайре;» сүзләренә алыштырырга;

1.2) 2 пунктның 5 абзацына «әлеге абзацта күрсәтелгән һәр кайсының кадастр бәясе 300 миллион сумнан артып киткән җир кишәрлекләреннән гайре;» сүзләрен өстәргә.

2. Әлеге карар үз көчен 2025 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә җәелдерә.

3. Әлеге карарны Шумково авыл җирлегенең түбәндәге адреслар буенча урнашкан махсус стендларында: Татарстан Республикасы, Балык Бистәсе муниципаль районы, Шумково авылы, Үзәк урам, 4 йорт; Олы Укмас авылы, Үзәк урам, 42 йорт; Хутор авылы, Яшьлек урамы, 5 йорт; Әшнәк-Качкалак авылы, Югарыгы урам, 5 йорт һәм Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының http://ribnaya-sloboda.tatarstan.ru. веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында һәм http://pravo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге “Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталы”нда урнаштырырга.

4. Карарның үтәлешенә контрольлек итүне үземнең җаваплылыкта калдырам.

Шумково авыл җирлеге башлыгы
Балык Бистәсе муниципаль районы
Татарстан Республикасы А. Р. Гилазиева.